ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 12 » май 2025 ел** **№ 28**

**Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 6 декабрендәге “Үрнәк авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләреннән файдалану турында” 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 28 августындагы “Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы турында” 901 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы “Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында” 138 номерлы карары (29.03.2024 редакциясе), РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган РФдә янгынга каршы режим кагыйдәләре нигезендә, Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетының **2024 елның 6 декабрендәге** “Үрнәк авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләреннән файдалану турында” 42 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктына түбәндәге абзац өстәргә:

«Биеклеге 50 метрдан артыграк булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә һава пространствосыннан файдалану Россия Федерациясе һава хәрәкәтен

оештыруның Бердәм системасы оператив органы (алга таба - Вәкаләтле орган) рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.».

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында arsk.tatarstan.ru “Җирлекләр” бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Үрнәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе В.Р.Габделхаков

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "УРНЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" * ОГРН 1121690000264
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012727